Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар (ачык тыңлаулар) башлану турында
хәбәрнамә

1. Әлеге мәгълүмат белән Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районының 16:42:201101:609 кадастр номерлы, 1000,0 кв. м. мәйданлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар (ачык тыңлаулар) башлануы турында хәбәр итәбез: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Ибраһимов ур., 5 җ/к, (алга таба-проект).

2. Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

- Гариза;
- Күчемсез милекнең дәүләт реестрыннан өземтә;
- Автомойкага эскиз проекты;

3. Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар (ачык тыңлаулар) үткәрү тәртибе һәм сроклары:

Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар (ачык тыңлаулар) 27.12.2024 елдан 10.01.2025 елга кадәр уздырыла. Ачык тыңлаулар үткәрү процедурасына түбәндәге этаплар керә:

- иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәрнамә (ачык тыңлаулар);
- проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтка урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;
- проект экспозицияләрен үткәрү;
- җәмәгать фикер алышуларында (ачык тыңлауларда)катнашучылар җыелышларын үткәрү;
- иҗтимагый фикер алышулар (ачык тыңлаулар) беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- иҗтимагый фикер алышулар (ачык тыңлаулар) нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

4. Иҗтимагый фикер алышуларда (ачык тыңлауларда) катнашучылар даирәсе:

Проект буенча иҗтимагый фикер алышуларда (ачык тыңлауларда) катнашучылар булып түбәндәгеләр тора:

- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарның хокук ияләре.

5. Иҗтимагый фикер алышулар (ачык тыңлаулар) уздырыла торган территория:

- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе.

6. Проект экспозицияләрен ачу урыны һәм датасы:

- Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, адресы: ТР, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 нчы йорт - 27.12.2024 ел

7. Проект экспозицияләрен үткәрү сроклары:

27.12.2024 елдан 09.01.2025 елга кадәр

8. Экспозицияләрне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:

Эш көннәрендә 09.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш тәнәфесе – 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

9. Җәмәгать фикер алышуларында (ачык тыңлауларда) катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше:

27.12.2024 елдан 09.01.2025 елга кадәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – РФ ГрК) 51 статьясының 12 өлеше нигезендә идентификация узган иҗтимагый фикер алышуларда (ачык тыңлауларда) катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- рәсми сайт аша;

- язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә Татарстан Республикасы Чистай шәһәр Башкарма комитетының (архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге) ачык тыңлауларны оештыручы адресына түбәндәге адрес буенча: 422980, ТР, Чистай районы, Чистай шәһәре, К. Маркс урамы, 27 нче йорт, тел. (84342) 5-15-54 (9.00 дән 17.00 гә кадәр).

- ачык тыңлауларда каралырга тиешле проектның экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсенә (журналына) язу юлы белән түбәндәге адрес буенча: 422980, ТР, Чистай районы, Чистай ш., К. Маркс урамы, 27 нче йорт, тел. (84342) 5-15-54 (9.00 дән 17.00 гә кадәр).

Җәмәгать фикер алышуларында (ачык тыңлауларда) катнашучылар: РФ ГрК 51 статьясының 12 өлеше нигезендә идентификация узган, җәмәгать фикер алышуларында (ачык тыңлауларда) катнашучылар җыелышларын үткәрү барышында тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне язмача яисә телдән кертергә хокуклы.

10. Җәмәгать фикер алышуларында (ачык тыңлауларда)катнашучылар җыелышларын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:

проект буенча иҗтимагый фикер алышуларны (ачык тыңлауларны) 2025 елның 10 гыйнварында уздырырга:

- Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Конференц-залында түбәндәге адрес буенча: ТР, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Бебель ур., 129 нчы йорт, 14:00 сәгатьтә.

11. Проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат:

Проект Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) 27.12.2024 елдан түбәндәге сылтама буенча: https://chistopol.tatarstan.ru/publichnie-slushaniya-847337.htm урнаштырылачак.

12. Әлеге хәбәрнамәне Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Чистай шәһәр Башкарма комитеты
җитәкчесе И.Ф. Рәхимов